ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Школьная, д.1 , д. Смак Корса, Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктэп ур, 1 нче йорт, Курса Почпак авылы, Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366) 53-2-36 факс (84366) 53-2-36. E-mail Smk.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 26 » февраль **2026 ел** № 1

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Сеҗе авыл җирлеге территория-сендә “Авыл территорияләрен комплекслы үстерү” Россия Федерациясе дәүләт программа-сы буенча төзелгән (сатып алынган) торак урынны (торак йортны) сатып алу тәртибен раслау турында**

Авыл территорияләрендә, терәк торак пунктлар территорияләрендә һәм янәшәдәге территорияләрдә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына Авыл территорияләрендә, терәк торак пунктлары территорияләрендә һәм янәшәдәге территорияләрдә торак төзү (сатып алу) буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә торак урынга наем шартнамәсе буенча, “Авыл территорияләрен комплекслы үстерү” Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган Авыл территорияләрендә торак төзелешен үстерүгә һәм йорт биләмәләрен төзекләндерү дәрәҗәсен арттыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү Кагыйдәләренә кушымта итеп бирелә торган торак урынга наем шартнамәсе буенча финанс ярдәме күрсәтүгә субсидияләр бирү турындагы Нигезләмәнең 17 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Авыл территорияләрен комплекслы үстерү” Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру турында” 2020 елның 14 маендагы 387 номерлы карары белән расланган торак урыннарга наем шартнамәләре буенча торак алучылар исемлекләрен төзү, раслау һәм үзгәртү Тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта итеп бирелә торган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Сеҗе авыл җирлеге территориясендә “Авыл территорияләрен комплекслы үстерү” Россия Федерациясе дәүләт программасы буенча төзелгән (сатып алынган) торак урынны (торак йортны) сатып алуның тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сеҗе авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.В.Хамидуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СИЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1609012741

*Татарстан Республикасы*
*Арча муниципаль районы*
*Сеҗе авыл җирлеге карарына*
*“26” февраль 2026 №1*
*кушымта*

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Сеҗе авыл җирлеге территориясендә “Авыл территорияләрен комплекслы үстерү” Россия Федерациясе дәүләт программасы буенча төзелгән (сатып алынган) торак урынны (торак йортны) сатып алу тәртибе

### I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге карар Авыл территорияләрендә, терәк торак пунктлар территорияләрендә һәм янәшәдәге территорияләрдә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына Авыл территорияләрендә, терәк торак пунктлары территорияләрендә һәм янәшәдәге территорияләрдә торак төзү (сатып алу) буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә торак урынга наем шартнамәсе буенча, “Авыл территорияләрен комплекслы үстерү” Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган Авыл территорияләрендә торак төзелешен үстерүгә һәм йорт биләмәләрен төзекләндерү дәрәҗәсен арттыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү Кагыйдәләренә кушымта итеп бирелә торган торак урынга наем шартнамәсе буенча финанс ярдәме күрсәтүгә субсидияләр бирү турындагы Нигезләмәнең 17 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Авыл территорияләрен комплекслы үстерү” Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру турында” 2020 елның 14 маендагы 387 номерлы карары белән расланган торак урыннарга наем шартнамәләре буенча торак алучылар исемлекләрен төзү, раслау һәм үзгәртү Тәртибе (алга таба – Тәртип) нигезендә эшләнде.

Тәртип нигезендә төзелгән (сатып алынган) торак урыннар (торак йортлар) коммерциячел файдаланудагы торак фондына керә һәм гражданнарга Россия Федерациясе Гражданлык кодексы нигезендә торак урынны наем шартнамәсе буенча түләүле биләүгә һәм файдалануга бирелә.

1.3. Торак урынга наем шартнамәсендә гражданның эш бирүче белән хезмәт шартнамәсе буенча 5 елдан 10 елга кадәр (эш бирүче карары буенча) эш срогы карала, шул вакыттан соң граждан күрсәтелгән торак урынны (торак йортны) торак сатып алу (төзү) бәясенең 10 процентыннан артмаган бәягә (алга таба – торакның сатып алу бәясе), ә 10 елдан соң – 1 процентыннан

артмаган бәягә үз милкенә сатып алырга мөмкин. Торакның сатып алу бәясе күләмендә акчалар торак урынны (торак йортны) яллаучыларның теләге буенча күрсәтелгән срок дәвамында 5 елдан алып 10 елга кадәр ай саен (квартал саен) тигез өлешләрдә, түләүләрне вакытыннан алда кертү хокукыннан башка, түләнергә мөмкин.

Торак урынны (торак йортны) наемга алу өчен түләү Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 133 статьясы нигезендә билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең минималь күләменең 0,15 процентыннан артмаган күләмендә 1 кв.метр өчен билгеләнә.

1.4. Әгәр торак урын (торак йорт) муниципаль берәмлекнең һәм күрсәтелгән эш бирүченең гомуми милкендә булса, торак урынны наем шартнамәсендә түләүләрнең кемгә һәм нинди күләмдә кертелүе билгеләнә.

1.5. Торак урынга наем шартнамәсенең мөһим шартлары булып тора:

а) Торак урын (торак йорт) яллаучының хезмәт шартнамәсе буенча торак урын (торак йорт) бирелә торган авыл территорияләрендә, терәк торак пунктлар территорияләрендә, муниципаль район (шәһәр җирлеге, муниципаль округ, шәһәр округы) чикләрендәге янәшәдәге территорияләрдә торак урын (торак йорт) наем шартнамәсе рәсмиләштерелгән көннән алып кимендә 5 ел дәвамында эшләве, әлеге пунктның “б” пунктчасында күрсәтелгән очрактан тыш;

б) әгәр эш бирүченең торак урынга (торак йортка) гомуми милектәге өлешенә милек хокукы башка затларга күчә һәм граждан белән элекке эш бирүче арасында төзелгән хезмәт шартнамәсен өзүгә китерсә, гражданга торак урын (торак йорт) наем шартларында бирелгән Россия Федерациясе субъекты чикләрендәге авыл территорияләрендә, терәк торак пунктлар территорияләрендә, янәшәдәге территорияләрдә гражданның 6 айдан артмаган срокта эшкә урнашу хокукы.

1.6. Торак урынны (торак йортны) яллаучы шартларны үтәмәгән очракта, торак урынны (торак йортны) яллаучы торак урынны (торак йортны) сатып алу бәясе буенча үз милкенә сатып алу хокукыннан мәхрүм ителә.

Торак урынны (торак йортны) яллаучы әлеге Тәртипнең 1.5 пунктында каралган шартларны үтәмәгән очракта торак урынны (торак йортны) яллаучы торак урын (торак йорт) милекчесеннән (милекчеләреннән) торакның сатып алу бәясе күләмендә акчалар түләү счетына кертелгән акчаларны кире кайтаруны таләп итәргә хокуклы, шул исәптән суд тәртибендә.

1.7. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган, контракт буенча Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә яисә Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләрендә, хәрби формированиеләрдә һәм “Оборона турында”1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән органнарда хәрби хезмәт (хезмәт) узучы, аның Украина, Донецк Халык

Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашуы шарты белән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә яисә Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм итү турында контракт төзегән граждан (алга таба – хәрби хезмәткәр) һәлак булган (үлгән) очракта, әгәр ул махсус хәрби операция үткәрү чорында йә күрсәтелгән чордан соңрак бурычларны үтәгәндә, ләкин махсус хәрби операция үткәрү барышында бурычларны үтәгәндә алган гариплек (яралану, җәрәхәтләнү, контузия) яки авыру нәтиҗәсендә һәлак булса (үлсә), яки суд хәрби хезмәткәрне үлгән дип игълан итсә, шулай ук хәрби хезмәткәр Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә I төркем инвалид дип танылса, мондый хәрби хезмәткәрнең варислары әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән торак урынын торакның сатып алу бәясе буенча үз милкенә сатып алу хокукын саклап кала. Хәрби хезмәткәрнең үлеменә яки хәрби хезмәткәрне I төркем инвалид дип тануга китергән гариплек (яралану, җәрәхәтләнү, контузия) яки авыруның Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә аның махсус хәрби операция үткәрү барышында бурычларын үтәве белән сәбәп бәйләнеше хәрби-табиб комиссияләре һәм (яисә) Федераль медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан билгеләнә.

## II. Торак урынны (торак йортны) сатып алу тәртибе

2.1. “Авыл территорияләрен комплекслы үстерү” Россия Федерациясе дәүләт программасы буенча төзелгән (сатып алынган) торак урынны (торак йортны) сатып алу өчен гражданин Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетына (алга таба – Башкарма комитетка) әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча төзелгән гариза тапшыра.

Гаризага түбәндәге документлар (документларның күчермәләре) кушып бирелә:

1) аңа (аның гаилә әгъзаларына) коммерция наемы шартларында бирелгән торак урынны (торак йортны) сатып алу турында гражданның (варисларының – торак урынны вакытыннан алда сатып алган очракта) шәхси гаризасы;

2) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документлар, гаилә составы турындагы документлар (паспортлар, балаларның туу турындагы таныклыклар, никахлашу (өзелү) турында таныклык) – төп нөсхәләре белән күчермәләр;

3) таныкланган хезмәт шартнамәсе, хезмәт кенәгәсе, электрон хезмәт кенәгәсе күчермәсе;

4) иминиятләштерелгән затның индивидуаль шәхси счеты торышы турында белешмәләр;

5) коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычлар булмау турында белешмәләр;

6) торак урынны вакытыннан алда сатып алу шартларын раслый торган документларның күчермәләре (1.7 пункт);

7) мирас алу хокукы турында таныклык (торак урынны вакытыннан алда сатып алганда);

8) шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык (тәкъдим ителә торган форма әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада китерелгән).

2.2. Башкарма комитет әлеге Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә тапшырылган документларны һәм күрсәтелгән документларны тапшырган көннән алып 10 эш көне эчендә карый һәм торак урынны сату турында карар чыгара яисә гражданга сатудан баш тарту турында хәбәрнамә җибәрә.

2.3. Торак урынны (торак йортны) сату турында карар кабул ителгән очракта, Башкарма комитет кабул ителгән карар турында гражданга тиешле карар кабул ителгән вакыттан алып өч эш көне эчендә хәбәр итә.

2.4. Гражданга торак урынны (торак йортны)сатып алудан баш тарту турында Карар кабул итү өчен нигезләр:

1) документларны (документларның күчермәләрен) тулы күләмдә тапшырмау йә гаризада һәм (яисә) документларда (документларның күчермәләрендә) тулы булмаган документлар һәм (яисә) дөрес булмаган белешмәләр булуы;

2) гражданның хезмәт эшчәнлеген шартнамәдә билгеләнгән вакыттан кимрәк башкаруы;

3) сатып алу бәясе өчен түләү, торак урынны наемга түләү яисә гариза бирелгән айга кадәрге чорда коммуналь түләүләр буенча бурычлар булу.

2.5. Торак урынны сатып алудан баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез булган хәлләр бетерелгәннән соң, граждан Башкарма комитетка гариза белән кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2.6. Торак урынның бәясе тәртипнең 1.3 пункты нигезендә билгеләнә.

2.7. Торакның сатып алу бәясе күләмендә акчалар торак урынны яллаучыларның теләге буенча күрсәтелгән срок дәвамында 5 елдан алып 10 елга кадәр ай саен (квартал саен) тигез өлешләрдә, түләүләрне вакытыннан алда кертү хокукыннан башка, түләнергә мөмкин.

2.8. Сатып алына торган торак бина (торак йорт) урнашкан җир кишәрлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Россия Федерациясе Җир кодексының 3920 статьясы белән күздә тотылган очракларда Татарстан Республикасы милкендәге яки аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән, аларда биналар, корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрен мондый биналар, корылмалар йә алардагы бүлмәләр

милекчеләренә сату турында” 2012 елның 3 октябрендәге 827 нче номерлы карарына үзгәреш кертү турында” карары нигезендә аерым сатып алына.

2.9. Сату-алу шартнамәсен төзү, сату-алу шартнамәсен төзүгә бәйле чыгымнар, хокукны теркәү чыгымнары сатып алучыга йөкләнә. Торак урынга (торак йортка) милек хокукының гражданга күчүе Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

2.10. Торак урынга (торак йортка) милек хокукы торак урынның (торак йортның) сатып алу бәясен түләгәннән соң гражданга күчә.

2.11. Торак урын (торак йорт) сатып алудан алынган акчалар Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Сеҗе авыл җирлеге бюджетына күчерелергә тиеш.

*Татарстан Республикасы*
*Арча муниципаль районының*
*Сеҗе авыл җирлеге территориясендә “Авыл территорияләрен комплекслы үстерү”*
*Россия Федерациясе дәүләт программасы буенча төзелгән (сатып алынган)*
*торак урынны (торак йортны) сатып алу тәртибенә*
*1нче кушымта*

Форма

Кемгә:_______________________________________________
_______________________________________________
_______________________________________________,
Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта)
_______________________________________________
Адресы буенча яшәүче:
_______________________________________________
_______________________________________________,
_______________________________________________,
Телефон номеры (булган очракта)
_______________________________________________
Электрон почта адресы (булган очракта)

**ГАРИЗА**

Мин_________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта)
паспорт_________________, бирелгән
_______________________________________ ___________________________
(серия, номер) (кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________,
миңа
минем һәм ____________________________________________________________
(милекче (милекчеләрнең) тулы исеме)
Арасында төзелгән ______________ № ___________
(төзү датасы ) (номер)
торак урынга наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урынны (торак йортны) торак төзелешенең (сатып алуның) исәп-хисап бәясенең _______ процентына тигез бәядән сатып алуны килештерүегезне сорыйм.

Мин “Авыл территорияләрен комплекслы үстерү” Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган “Авыл территорияләрен комплекслы үстерү” Россия Федерациясе дәүләт программасында катнашучы булып торам һәм ____ елга торак урынга наем

шартнамәләре буенча торак алучы гражданнарның җыелма исемлегенә кертелдем.

Торак урынны (торак йортны) сатып алу хокукын гамәлгә ашыру өчен мин торак урынны наем шартнамәсенең мөһим шартларын үтәдем. Торак урынга наем шартнамәсе төзелгән көннән башлап мин ___________ ел дәвамында чикләрендә бирелә торган торак бина (торак йорт) урнашкан муниципаль берәмлекнең авыл территориясендә (кирәклесен билгеләргә):

☐ ____________________________ (хезмәт килешүе (хезмәт килешүләре) буенча хезмәт эшчәнлеге башкардым _______________________ _____________________________________________________________________

(эш бирүченең (эш бирүчеләрнең) тулы исеме)

Гаризага түбәндәге документлар (документларның күчермәләре) кушып бирелә ____ биттә:

1) ____________________________________________________________________;

(документ исеме һәм аның реквизитлары)

2) ____________________________________________________________________;

(документ исеме һәм аның реквизитлары)

3) ____________________________________________________________________.

(документ исеме һәм аның реквизитлары)

_____________________________________ _______________ ____________

(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, этисенең исеме (булган очракта) | (имза) | (дата)

_________________________________ _______________ ____________________

(гаризаны кабул итеп алган вәкаләтле затның вазыйфасы) | (имза) | (дата)

*Татарстан Республикасы*
*Арча муниципаль районының*
*Сеҗе авыл җирлеге территориясендә “Авыл территорияләрен комплекслы үстерү” Россия Федерациясе дәүләт программасы буенча төзелгән (сатып алынган) торак урынны (торак йортны) сатып алу тәртибенә*
*2нче кушымта*

Тәкъдим ителә торган форма

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык
(“Шәхси мәгълүматлар турында” 2006 елның 27 июлендәге
152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә)

Мин,_______________________________________________________________
(ФИО (әтисенең исеме – булган очракта)
Шәхесне раслаучы документ ________ серия __________№ _____________,
(документ төре)
Адресы буенча теркәлгән: ____________________________________________,
“Шәхси мәгълүматлар турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә __________________ (алга таба – Оператор) ___________ максатында ризалык бирәм.

Эшкәртүгә мин ризалык биргән шәхси мәгълүматларым исемлеге: фамилия, исеме, атасының исеме, гражданлык, җенес, яшь, туган көнеһәм урын, шәхесне таныклаучы төп документның номеры, күрсәтелгән документның бирелгән датасы һәм аны биргән орган турындагы белешмәләр, яшәү урыны буенча теркәлү адресы, фактта яшәү адресы, салым түләүченең идентификация номеры, иминият номеры индивидуаль шәхси счет, кәрәзле телефон номеры, электрон почта адресы, гаилә хәле, белем, эш (хезмәт) урыны, шул исәптән алдагылары турында, белешмәләр, фотосурәтләр һәм видеоязмалар.

Операторга үземнең шәхси мәгълүматларымны автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча башкарыла торган эшкәртүне башкарырга рөхсәт итәм: җыю, язу, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), алу, куллану, тапшыру (бирү, керү), шәхессезләндерү, блоклау, бетерү, юк итү.

Оператор минем шәхси мәгълүматларымны Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә эшкәртүне гарантияли, дип хәбәр иттем.

Әлеге ризалык шәхси мәгълүматларны эшкәртү максатларына ирешкәнче яисә мәгълүматны саклау срогы дәвамында гамәлдә була. Бу ризалык минем язма гаризам буенча кире алынырга мөмкин.

«______»____________20______ел

Шәхси мәгълүмат субъекты:

_________________/_______________________(имза/ФИО)